| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br><br>СОВЕТ<br>АЛЬМЕТЬЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br><br>ӘЛМӘТ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«29» март 2023г. г. Альметьевск № 215

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советы Регламенты турында» 2006 елның 3 февралендәге 38 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 26 январендагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставы нигезендә

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советы Регламенты турында» 2006 елның 3 февралендәге 38 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2009 елның 25 декабрендәге 368 номерлы, 2014 елның 4 мартындагы 369 номерлы, 2015 елның 13 мартындагы 456 номерлы, 2015 елның 10 декабрендәге 33 номерлы, 2018 елның 15 ноябрендәге 261 номерлы, 2020 елның 13 маендагы 371 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- карарга кушымтада:

1.1. 13 статьяның 2 өлешендә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 31 статьяның 1 өлешендә «, ә ул булмаганда Район башкарма комитеты җитәкчесе» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.3. 59 статьяның 4 өлеше «кабул ителә» сүзеннән соң «күпчелек белән» сүзләре белән тулыландырыла;

1.4. 62 статьяның 1 өлешендә «өчтән ике» сүзләрен «күпчелекнең өчтән икесе» сүзләренә алмаштырырга;

1.5. 62 статьяның 2 өлешендә «өчтән ике» сүзләрен «күпчелекнең өчтән икесе» сүзләренә алмаштырырга;

1.6. 63 статьяның 1 өлешендәге 7 пунктында «Район сайлау комиссиясе әгъзаларын билгеләп кую турында,» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.7. 63 статьяның 1 өлешендәге 13 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

1.8. 17 бүлекнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17 бүлек. Районның контроль-хисап палатасы рәисе, рәис урынбасары һәм аудиторларын билгеләп кую һәм вазыйфаларыннан азат итү. Районның Финанс-бюджет палатасы рәисе, Җир-мөлкәт мөнәсәбәтләре һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеге комитеты рәисе вазыйфасын билгеләү һәм азат итү. Әлмәт муниципаль районы Иҗтимагый Советы әгъзаларын раслау»;

1.9. 75 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Районның Контроль-хисап палатасы рәисе үз вазыйфасына Район башлыгы тәкъдиме белән Район Советы белән билгеләнә һәм вазыйфасыннан азат ителә.

2. Районның контроль-хисап палатасы рәисе урынбасары һәм аудиторлары үз вазыйфасына район Советы белән Районның Контроль-хисап палатасы рәисе тәкъдиме буенча билгеләнә һәм вазыйфасыннан азат ителә.»;

1.10. 76 статьяда «Сайлау турындагы карар» сүзләрен «билгеләү турындагы карарлар» сүзләренә, «һәм урынбасар» сүзләрен «, рәис урынбасары һәм аудиторлар» сүзләренә алмаштырырга;

1.11. 77 статьяның 1 өлешендә «Районның мөлкәти һәм җир мөнәсәбәтләре палаталары» сүзләрен «Районның җир-мөлкәт мөнәсәбәтләре һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеге комитеты» сүзләренә алмаштырырга, «вазыйфасы» сүзен «вазыйфасы» сүзләренә алмаштырырга һәм үз вазыйфасыннан азат ителә»;

1.12. 77 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Районның Финанс-бюджет палатасы рәисе һәм Җир-мөлкәт мөнәсәбәтләре һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеге комитеты рәисе вазыйфасына билгеләү яисә аларны вазыйфасыннан азат итү турындагы карарлар район Советы депутатларының билгеләнгән саныннан күпчелек тавыш белән ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә.»;

1.13. 18 бүлекне «Район сайлау комиссиясе әгъзаларының вәкаләтләрен билгеләү һәм вакытыннан алда туктату» башлыгы үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәренең Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны районның законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Парфилова Н.В.).

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов

«СОВЕТ АЛЬМЕТЬЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА»